# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2024 елның 22 ноябре** **№ 2**

**2025 елда Кукмара муниципаль районының Зур Кукмара авылы торак пунктында гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә Татарстан хәл итте:

1.Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Зур Кукмара авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә

2.Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

**1) Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урамнарны яктырту өчен, энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру);

**2) Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су суырту башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су суырту башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, артезиан скважиналарын ремонтлау; яңа суүткәргеч челтәрләрен төзү, ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча хезмәтләр һәм эшләр өчен түләү)

**3) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр)** (Зур Кукмара авылында чишмәләр территориясен төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү)

**4) Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту** (яр буе зонасын карап тоту, яшелләндерү, проект-смета документациясен эшләү)

**5) Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү** (янгын гидрантларын сатып алу, урнаштыру һәм ремонтлау, янгын гидрантларын комплектлау, проект-смета документларын эшләү)

**6) Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) түгел) һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү** (Зур Кукмара авылы һәйкәлен төзү, ремонтлау һәм карап тоту, проект-смета документациясен эшләү)

**7) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту** (юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыр.; Зур Кукмара авылының урам-юл челтәрен карап тоту, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; Зур Кукмара авылы урамнарын асфальтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Зур Кукмара авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү; Зур Кукмара авылында автомобиль күпере төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру)

**8) Тротуарлар төзү, ремонтлау** (Зур Кукмара авылындагы «Быргы» чишмәсенә бара торган җәяүлеләр тротуарын төзекләндерү)

**9) Торак пункт территориясен төзекләндерү** (Балалар уен мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Ял зоналарын булдыру һәм төзекләндерү буенча чаралар үткәрү; Сабантуй бәйрәме уздыру урыны территориясен төзү һәм төзекләндерү; Зур Кукмара стадионын яктырту алу һәм урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту; Зур Кукмара авылында эскәмияләр һәм спорт инвентарьлары сатып алу, урнаштыру; халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү)

**10) Тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру** (Зур Кукмара авылында тукталыш павильоннарын буяу өчен буяулар сатып алу, проект-смета документларын эшләү)

**11) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өстендәге үтүләрне ремонтлау** (Зур Кукмара авылында Нурминкә елгасы аша Эшчеләр, М. Җәлил, Вахит, Октябрь, Колхоз, Х. Туфан, Елга аръягы урамнарына җәяүлеләр күперен төзекләндерү; мәчеттән алып Зур Кукмара стадионына кадәр җәяүлеләр күперен яшелләндерү һәм төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү; Зур Кукмара авылында җәяүлеләр күперен төзү, проект документларын эшләү)?

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Зур Кукмара авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Хәнәфиев